ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» октября 2021 ел №351

2021 елның 2 яртыеллыгына социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның кереме һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының 2021 елның беренче яртыеллыгына бәясе нормативы һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының 2021 елның I кварталына уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2020 елның 24 декабрендәге 852/пр номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елның 2 яртыеллыгына гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге чик күрсәткечләрен, аларны аз керемлеләр дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында, кушымта нигезендә билгеләргә:

1.1 Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга кеременең чик әһәмияте 19 050 сум 80 тиен күләмендә;

1.2 гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге, салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткече:

1.2.1 ялгыз яшәүче гражданнар өчен – 1 055 772 сум;

1.2.2 ике кешелек гаилә өчен – 2 111 544 сум;

1.2.3 өч кешелек гаилә өчен – 3 167 316 сум;

1.2.4 дүрт кешелек гаилә өчен – 4 223 088 сум;

1.2.5 биш кешелек гаилә өчен – 5 278 860 сум;

1.2.6 алты кешелек гаилә өчен – 6 334 632 сум;

1.2.7 җиде кешелек гаилә өчен – 7 390 404 сум;

1.2.8 сигез кешелек гаилә өчен – 8 446 176 сум.

2. Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 бүлекләрендә күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдаланырга, гражданнарны аз керемлеләр дип таныганда һәм аларны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар исәбенә куйганда һәм торак шартларын яхшыртканда файдаланырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 01 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

атарстан Республикасы
Әгерже муниципаль районы
Башкарма комитетынын
22.10.2021 № 351
карарына кушымта

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен исәпләү**

1. Базар бәясенең хисап күрсәткече:

СЖ = НП х РС х РЦ, кайда

СЖ - базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яки мөлкәт хакынын ин чик күләме;
НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;
РС - гаилә әгъзалары саны;
РЦ - ТР буенча РФ Төбәкләр үсеше министрлыгы раслаган торак урыны мәйданының бер квадрат метрының уртача исәп-хисап бәясе.

1) Ялгыз яшәүче кеше өчен:
СЖ = 18 х 1 х 58 654 = 1 055 772 сум.

2) ике кешелек гаилә өчен:
СЖ = 18 х 2 х 58 654 = 2 111 544 сум.

3) өч кешелек гаилә өчен:
СЖ = 18 х 3 х 58 654 = 3 167 316 сум.

4) дүрт кешелек гаилә өчен:
СЖ = 18 х 4 х 58 654 = 4 223 088 сум.

5) биш кешелек гаилә өчен:
СЖ = 18 х 5 х 58 654 = 5 278 860 сум.

6) алты кешелек гаилә өчен:
СЖ = 18 х 6 х 58 654 = 6 334 632 сум.

7) җиде кешелек гаилә өчен:
СЖ = 18 х 7 х 58 654 = 7 390 404 сум.

8) сигез кешелек гаилә өчен:
СЖ = 18 х 8 х 58 654 = 8 446 176 сум

2. Гаиләнен һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнен иң чик күләмен исәпләү.

Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең ин чик күләме формула буенча билгеләнә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС) -КП) / (0,3 х РС), кайда

ПД - СЖ исәпләү бәясе буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача җыелма керемнең чик әһәмияте;
СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече, ул формула буенча билгеләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ, кайда:

НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС- гаилә әгъзалары саны;

РЦ - Татарстан Республикасында торак урын сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмаган торак урын мәйданынын бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе;

ПС - Бер ай эчендә кредит буенча процент ставкасы (елына 7%, ягни аена 7/100/12 = 0,0058);

КП - Кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (20х12=240 айлар саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән нисбәте.

Торак урыны мәйданынын бер квадрат метрының уртача базар бәясе Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгынын "2021 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыннын гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында" боерыгы белән Татарстан Республикасы буенча 53 919 сум күләмендә билгеләнде.

Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик кыйммәтен исәпләү:

1) Ялгыз яшәүче кеше өчен:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС) - КП) / (0,3 х РС) = 0,7 х 1 055 772 х 0,0058 / (1 - (1 + 0,0058) - 240) / (0,3 х 1) = 4286,43 / 0,75/0,3 = 19040,80 сум.

2) ике кешелек гаилә өчен:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС) - КП) / (0,3 х РС) = 0,7 х 2 111 544 х 0,0058 / (1- (1 + 0,0058) - 240) / (0,3 х 2) = 8572,86 / 0,75/0,6 = 19040,80 сум.

3) өч һәм аннан күбрәк кешелек гаилә өчен:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС) - КП) / (0,3 х РС) = 0,7 х 3 167 316 х 0,0058 / (1 - (1 + 0,0058) - 240) / (0,3 х 3) = 12859,30 / 0,75/0,9 = 19040,80 сум.